**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**СОВЕТ АЛЬКЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
422870, с.Базарные Матаки,
ул. С.Крайнова, д.58

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘЛКИ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**
422870, РТ Базарлы Матак авылы,
С. Крайнов ур., 58

Телефон: (84346) 20-0-26, 21-0-48, факс: (84346) 21-7-57. E-mail: alkay@tatar.ru, сайт: alkeevskiy.tatarstan.ru.

# КАРАР

2020 елның 19 марты 297№

Татарстан Республикасы "Әлки муниципаль районы"
муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр
һәм өстәмәләр кертү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль закон (соңгы үзгәрешләр белән), 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Әлки районы прокуратурасының хокукый инициативасын өйрәнеп,Татарстан Республикасының «Әлки муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставының 92,93 статьясына нигезләнеп Әлки муниципаль районы Советы Карар итте:

1. Татарстан Республикасының «Әлки муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә (1 нче кушымта).
2. Әлеге карар гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә үз көченә керә.
3. «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы» Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карарны гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә җибәрергә.
4. «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карарын Татарстан Республикасының «Әлки муниципаль районы» Уставы статьяларының яңа редакциясен дәүләт теркәвенә алганнан соң Әлки муниципаль районының рәсми http://alkeevskiy.tatarstan.ru сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми pravo.tatarstan.ru порталында да халыкка җиткерергә һәм бастырырга.
5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Әлки муниципаль районы башлыгы урынбасарына йөкләргә.

Татарстан Республикасы Әлки
муниципаль районы Советы Рәисе: А. Ф. Никошин

Совет [Алькеевского] муниципального района РТ

Татарстан Республикасы "Әлки муниципаль районы"
муниципаль берәмлеге Советының 2020 елның
19 мартындагы 297 номерлы карарына
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы "Әлки муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр

1)6 статьяда («Муниципаль районның җирле әһәмияттәге мәсьәләләре»).
1 пунктның 8 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: ,
«8) милләтара һәм конфессияара татулыкны ныгытуга юнәлдерелгән чаралар эшләү һәм гамәлгә ашыру, Россия Федерациясе халыкларының телләрен һәм мәдәниятен яклау һәм үстерү, муниципаль район территориясендә яшәүче аз санлы төп халыкның һәм башка милли азчылыкның хокукларын гамәлгә ашыру, мигрантларның социаль һәм мәдәни адаптациясен тәэмин итү, милләтара (этникара) конфликтларны профилактикалау»;

1 пунктның 16 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«16) тиешле муниципаль районнар территорияләрендә каты коммуналь калдыкларны туплау (шул исәптән аерым туплау), җыю, транспортировкалау, эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, күмү эшчәнлеген оештыруда катнашу;»;

1 пунктның 17 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

«17) муниципаль районны территориаль планлаштыру схемасын раслау, муниципаль районны территориаль планлаштыру схемасы нигезендә әзерләнгән территорияне планлаштыру документларын раслау, муниципаль район территориясендә гамәлгә ашырыла торган шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итүнең мәгълүмат системасын алып бару, муниципаль ихтыяҗлар өчен муниципаль район чикләрендә җир кишәрлекләрен резервлау һәм алу, планлаштырыла торган индивидуаль торак яки бакча йорты төзелеше объектының җир кишәрлегендә бакча йортын урнаштыруның билгеләнгән параметрларына туры килүе һәм индивидуаль торак төзелеше объектын яисә җир кишәрлегендә бакча йортын урнаштыруның мөмкин булуы турында хәбәрнамәләр, тиешле авылара территорияләрдә урнашкан җир кишәрлекләрендә шәхси торак төзелеше объектларын яки бакча йортларын төзегәндә яки үзгәртеп корганда, төзелгән яки үзгәртеп корылган индивидуаль торак төзелеше объектының яки бакча йортының шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында закон таләпләренә туры килүе яисә туры килмәве турында хәбәрнамәләр, авылара территориядә урнашкан бинаны сүтү турында Россия Федерациясе граждан законнары нигезендә карар кабул итү, авылара территориядә урнашкан үзирекле корылмаларны сүтү яки аны билгеләнгән таләпләргә туры китерү турында карар, максатчан билгеләнеше буенча кулланылмаган яки Россия Федерациясе законнарын бозып файдаланыла торган һәм авылара территориядә урнашкан җир кишәрлеген тартып алу турында карар, авылара территориядә урнашкан үзирекле корылманы сүтүне гамәлгә ашыру, яки аны Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында каралган очракларда билгеләнгән таләпләргә туры китерү **авылара территориядә урнашкан җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын бирү»;**

6 статьяның 1 бүлеге 40 пунктында **(«Муниципаль районның җирле әһәмияттәге мәсьәләләре »):** «торак биналар» сүзләрен «күпфатирлы йортта биналар» сүзләренә алмаштырырга;

8 статьяның 3 пунктында (**«Авыл җирлекләре территорияләрендә районның җирле үзидарә органнары тарафыннан хәл ителә торган башка мәсьәләләр»):** «торак биналар» сүзләрен «күпфатирлы йортта биналар» сүзләренә алмаштырырга;

21 статьяга (**« Җәмәгать тыңлаулары, иҗтимагый фикер алышулар»):**

2 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

2. Җәмәгать тыңлаулары халык, район Советы, район Башлыгы, үз вәкаләтләрен контракт нигезендә башкаручы район Башкарма комитеты җитәкчесе инициативасы белән үткәрелә.
Халык инициативасы белән яки район Советы тарафыннан үткәрелә торган җәмәгать тыңлаулары район Советы, ә район Башлыгы яки үз вәкаләтләрен контракт нигезендә башкаручы район Башкарма комитеты җитәкчесе инициативасы белән үткәрелә торган нары район Башлыгы тарафыннан билгеләнә.»;

3 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:
«Җәмәгать тыңлауларын оештыру һәм уздыру тәртибе муниципаль берәмлек халкына җәмәгать тыңлаулары үткәрү вакыты һәм урыны турында алдан хәбәр итүне күздә тотып, муниципаль хокукый акт проекты белән алдан таныштырып, муниципаль берәмлек халкының җәмәгать тыңлауларында катнашуын тәэмин итә торган башка чараларны кулланып, муниципаль берәмлек уставы һәм( яисә) муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органының норматив хокукый актлары белән билгеләнә, кабул ителгән карарларның дәлилләнгән нигезләмәсен дә кертеп, җәмәгать тыңлаулары нәтиҗәләре бастырып чыгарыла( халыкка җиткерелә) »;

31 статьяга(**« Район Советы депутаты статусы»):**

6 пунктның 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

1) Россия Федерациясе Президенты яки Россия Федерациясе Хөкүмәте акты нигезендә оешманың коллегиаль органы эшчәнлегендә түләүсез нигездә катнашудан тыш, эшмәкәрлек эшчәнлеге белән шәхсән яки ышанычлы затлар аша шөгыльләнергә, коммерция оешмасы белән идарә итүдә яки коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә катнашу (Россия Федерациясе субъекты муниципаль берәмлекләр советы, муниципаль берәмлекләрнең башка берләшмәләре, сәяси партия идарәсендә, башка иҗтимагый оешма, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативлары, күчемсез милек милекчеләр ширкәтләре съездында( конференциясендә) яки гомуми җыелышта катнашудан тыш); муниципаль хокукый актлар нигезендә, оешманы гамәлгә куючының вәкаләтләрен муниципаль берәмлек исеменнән гамәлгә ашыру тәртибен яки муниципаль милектәге акцияләр белән идарә итү тәртибе (устав капиталындагы өлешләр) билгели торган гамәлгә куючы( акционер, катнашучы) муниципаль берәмлекнең идарә органнарында һәм оешманың ревизия комиссиясендә муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә тәкъдим итү; федераль законнарда каралган башка очраклар;

8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Район Советы депутаты 2008 елның 25 декабрендәге «Коррупциягә каршы көрәш турында» 273-ФЗ номерлы Федераль закон һәм башка федераль законнар белән билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны, бурычларны үтәргә тиеш. 2008 елның 25

декабрендәге "Коррупциягә каршы көрәш турында" 273-ФЗ номерлы Федераль закон, 2012 елның 3 декабрендәге «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар һәм аларның керемнәренә башка затлар чыгымнарының туры килүен контрольдә тоту турында» 230-ФЗ номерлы Федераль закон, 2013 елның 7 маендагы «Аерым категориядәге затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм счетлар (кертемнәр) булдыруны, акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында» 79-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны, бурычларны үтәмәгән очракта, әгәр 2003 елның 06 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законда башкасы каралмаган булса, район Советы депутаты вәкаләтләре вакытыннан алда туктатыла.

10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10. 2008 елның 25 декабрендәге "Коррупциягә каршы көрәш турында" 273-ФЗ номерлы Федераль закон, 2012 елның 3 декабрендәге «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар һәм аларның керемнәренә башка затлар чыгымнарының туры килүен контрольдә тоту турында» 230-ФЗ номерлы Федераль закон, 2013 елның 7 маендагы «Аерым категориядәге затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм счетлар (кертемнәр) булдыруны, акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында» 79-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән , әлеге статьяның 9 пункты нигезендә үткәрелгән тикшерү нәтиҗәсендә чикләүләрне, тыюларны, бурычларны үтәмәү фактларын ачыклаганда, Татарстан Республикасы Президенты район Советы депутаты вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату яки күрсәтелгән затларга карата башка төр җаваплылык чарасын куллану турында тиешле карарлар кабул итәргә вәкаләтле район Советына яки судка гариза белән мөрәҗәгать итә.
Татарстан Республикасы Президенты муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутатының вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында гариза белән мөрәҗәгать иткән очракта, вәкаләтләрне вакытыннан алда туктату өчен нигез барлыкка килгән көн әлеге гаризаны муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органына кергән көн була.»;

34 статьяга **(«Район Советы компетенциясе»):**

1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«34) Россия Федерациясенең шәһәр төзелеше кодексы нигезендә районның территориаль планлаштыру документларын, башка шәһәр төзелеше документларын раслау»;

48 статьяга **(«Башкарма комитет вәкаләтләре»):**

5 пунктчаның 11 абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

7 пунктның 19 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«-муниципаль район территориясендә яшәүче Россия Федерациясе халыкларының милләтара һәм конфессияара татулыгын ныгытуга, телләрен һәм мәдәниятен үстерүгә, аз санлы төп халыкларның һәм башка милли азчылыкларның хокукларын гамәлгә ашыруга,

мигрантларның социаль һәм мәдәни җайлашуын тәэмин итүгә, милләтара (этникара) конфликтларны профилактикалауга юнәлтелгән чаралар эшли һәм гамәлгә ашыра»;

52 статьяга (**«Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вәкаләтләре»):**

6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарларын билгели һәм вазыйфаларыннан азат итә, алар арасында вазыйфаларны бүлә, Әлки муниципаль районының муниципаль хезмәткәрләрен һәм башка хезмәткәрләрен вазыйфага билгели һәм вазыйфадан азат итә, аларның эшчәнлеген контрольдә тота, аларга карата кызыксындыру һәм дисциплинар җаваплылык чараларын куллана;

56 статьяга (**«Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының контроль-хисап палатасы» муниципаль казна учреждениесе»):**

3 пунктка түбәндәге эчтәлекле өченче абзац өстәргә:

«Якын (ата-аналар, ир белән хатын, балалары, абый-энеләре, апа-сеңелләре, шулай ук ире яки хатынының абый-энеләре, апа-сеңелләре, ата-аналары, һәм балаларының ире яки хатыны) яисә районның вәкиллекле органы рәисе, район башлыгы, җирле администрация башлыгы, тиешле район территориясендә урнашкан суд һәм хокук саклау органнары җитәкчеләре белән туганлык булганда, граждан районның контроль-хисап органы рәисе, рәис урынбасары һәм аудиторы вазыйфасына билгеләнә алмый, ә муниципаль хезмәткәр рәис, районның контроль-хисап органы рәисе урынбасары һәм аудиторы вазыйфасын били алмый».

69 статьяга (**«Ышанычны югалтуга бәйле рәвештә затларны, муниципаль вазыйфаларны эштән азат итү (вазыйфасыннан азат итү»)):**

түбәндәге эчтәлекле 3 пункт өстәргә:
«3. Үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре һәм хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында бозып күрсәтүе җитди булмаган дөрес яки тулы булмаган мәгълүмат биргән район Советы депутатына, түбәндәге җаваплылык чаралары кулланылырга мөмкин:
1) кисәтү;
2) депутатны, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасын муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органында, җирле үзидарәнең сайланулы органында вазыйфасыннан азат итү, аның вәкаләтләре чоры тәмамланганчы, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органында, җирле үзидарәнең сайланулы органында вазыйфалар биләү хокукыннан мәхрүм итү;
3) даими нигездә вәкаләтләрне гамәлгә ашырудан аның вәкаләтләре чоры туктатылганчы даими нигездә вәкаләтләр башкару хокукыннан мәхрүм итеп азат итү;
4) муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органында, җирле үзидарәнең сайланулы органында аның вәкаләтләре срогы тәмамланганчы вазыйфаларны биләүне тыю;
5) вәкаләтләр срогы тәмамланганчы даими нигездә вәкаләтләрен үтәүне тыю.»;

91 статьяга (**«Муниципаль финанс контроле»):**

1 пунктның 1 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль финанс контроле бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга сала торган хокукый актлар нигезләмәләренең, җәмәгать норматив йөкләмәләрне тәэмин итә торган хокукый актлар һәм физик затларга Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларыннан башка түләүләр буенча йөкләмәләр, шулай ук бюджеттан акчалар бирү турында дәүләт (муниципаль) контрактлары, шартнамәләр (килешүләр) шартларын үтәлешен тәэмин итү максатларында гамәлгә ашырыла.»;

2 пунктта «бюджет хокук мөнәсәбәтләре өлкәсендә» сүзләрен төшереп калдырырга;

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Эчке муниципаль финанс контроле Башкарма комитет органнары (вазыйфаи затлары) булган муниципаль финанс контроле органнарының контроль эшчәнлеге булып тора.».